ГЛАВА ОМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“29” октября 2019 г. — № 5

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Омар Пучинкәсә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Омар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Омар Пучинкәсә авылы , Нагорный урамында, 23 номерлы йорт янында 2019 елның 12 ноябрь сәгать 10.00 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Омар Пучинкәсә авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Омар Пучинкәсә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Омар Пучинкәсә авылы  Нагорная урамы, Көньяк урамы (сатып алу, ташу, вак таш җәю, грейдлау, килешү буенча эш өчен түләү);

« ӘЙЕ»                                                           «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башкарма комитетына Омар Пучинкәсә авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге башлыгы:                    Л.Н.Хәбибуллин